МИНИСТЕРСТВО ПРОМЫШЛЕННОСТИ И ТОРГОВЛИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

05.07.2021 Казан шәһәре № 123-ОД

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) буенча конкурс уздыру турында нигезләмә раслау хакында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына кертүгә конкурслар үткәрүнең бердәм методикасын раслау турында» 2018 елның 31 мартындагы 397 номерлы карары һәм «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы норматив хокукый актын законнарга туры китерү максатларында,

боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында кушымтада бирелгән нигезләмәне расларга.

2. Әлеге боерыкны министр урынбасарларына, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының структур бүлекчәләре җитәкчеләренә һәм хезмәткәрләренә җиткерергә.

3. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының түбәндәге боерыкларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар

резервына кертү) буенча конкурс уздыру турында нигезләмә раслау хакында» 2017 елның 19 декабрендәге 310-ОД номерлы;

«Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2017 елның 19 декабрендәге 310-ОД номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» 2020 елның 10 мартындагы 35-ОД номерлы.

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
министр А.Ә. Кәримов

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм
сәүдә министрлыгының 2021 елның
05.07.2021 № 123-ОД боерыгы
белән расланды

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында
Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын
биләү (кадрлар резервына кертү) буенча конкурс уздыру турында
нигезләмә

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Нигезләмә белән Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру буенча конкурс комиссиясенең (алга таба – конкурс комиссиясе) эшләү вакытлары һәм тәртибе, шулай ук Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру методикасы билгеләнә.

1.2. Министрлыкта Конкурс «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – Федераль закон) 22 статьясы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына кертүгә конкурслар үткәрүнең бердәм методикасын раслау турында» 2018 елның 31 мартындагы 397 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар хезмәтенә мәгълүмат технологияләрен кертүнең кайбер чаралары турында» 2018 елның 5 мартындагы 227 номерлы карары, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә кадрлар резервы турында нигезләмә раслау турында» 2011 елның 14 мартындагы ПУ-127 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче гражданнарга тест уздыруны оештыру мәсьәләләре» 2015 елның 11 декабрендәге ПУ-1192 номерлы Указы нигезендә уздырыла.

Конкурс дәүләт граждан хезмәте (алга таба – граждан хезмәте) вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүчеләрнең профессиональ дәрәҗәсен, аларның граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен билгеләнгән квалификация таләпләренә җавап бирүен бәя-

ләүдән гыйбарәт.

1.3. Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс Федераль закон нигезендә конкурс нигезендә биләнергә мөмкин булган граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы булганда сәнәгать һәм сәүдә министрының (аның вазыйфаларын башкаручы затның) (алга таба – министр) карары белән игълан ителә.

1.4. Министрлыкның кадрлар резервына кертүгә конкурс кадрлар бүлеге тарафыннан, Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү буенча белгечләргә мөмкин булган ихтыяҗын һәм Министрлыктагы кадрлар резервын ел саен бәяләү нәтиҗәләре буенча оештырыла. Министрлыкның кадрлар резервына кертүгә конкурс министр карары буенча игълан ителә.

1.5. Вакантлы вазыйфаны биләү (кадрлар резервына кертү) өчен конкурс Министрлыкның конкурс комиссиясе тарафыннан әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә үткәрелә.

1.6. Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс түбәндәге очракларда үткәрелми:

билгеле бер чорга биләнә торган «җитәкчеләр» һәм «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категориясендәге граждан хезмәте вазыйфасы вәкаләтләрен биләү өчен билгеләнгәндә;

ашыгыч хезмәт контракты төзелгәндә;

Федераль законның 28 статьясының 2 өлешендә, 31 статьясының 1 өлешендә һәм 60.1 статьясының 9 өлешендә каралган очракларда граждан хезмәткәрен дәүләт граждан хезмәтенең бүтән вазыйфасына билгеләгәндә;

граждан хезмәтендә кадрлар резервына кертелгән граждан хезмәткәрен (гражданинны) граждан хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә.

1.7. Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс түбәндәге очракларда үткәрелмәскә мөмкин:

алар буенча вазыйфаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, Министрлык боерыгы нигезендә расланучы вазыйфалар исемлегендә аерым граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә;

министр карары нигезендә, граждан хезмәтенең кече вазыйфалар төркеменә карый торган граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә.

1.8. Конкурс үткәрелә торган максатлар:

Россия Федерациясе гражданнарының конституциячел хокукларын, аларның сәләтләре һәм һөнәри әзерлекләре нигезендә дәүләт граждан хезмәтеннән бертигез файдалану мөмкинлеген, шулай ук дәүләт граждан хезмәткәрләренең конкурс ниге-

зендә вазыйфаи үсешкә хокукларын тәэмин итү;

граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә аеруча туры килә торган, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә торган һәм конкурста катнашуга кертелгән кандидатларның гомуми санынннан кандидатларны сайлап алу;

граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен Министрлыкның кадрлар резервын формалаштыру.

1.9. Конкурслар үткәргәндә хәл ителә торган бурычлар:

конкурс биремнәрен һәм процедураларны үтәгәндә барлык кандидатлар өчен тигез шартлар тәэмин итү;

кандидатларны объектив һөнәри әһәмияткә ия критерийлар нигезендә бәяләү;

конкурс процедуралары барышында алынган объектив һәм нигезләнгән күрсәткечләрне чагыштыру юлы белән, конкурста катнашучы затлар арасында граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларына (кадрлар резервына кертүгә) карата таләпләргә туры килә торган затларны билгеләү.

1.10. Кандидат конкурс комиссиясе карарына Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять бирергә хокуклы.

1.11. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) дәгъва белдергән, ләкин конкурста катнашуга кертелмәгән кандидатларның һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары язма гаризалары буенча конкурс тәмамланган көннән соң өч ел дәвамында аларга кайтарып бирелергә мөмкин. Әлеге чор тәмамланганчыга кадәр документлар Министрлык архивында саклана, аннан соң юкка чыгарылырга тиеш. Конкурста катнашу өчен электрон рәвештә тапшырылган документлар өч ел дәвамында саклана, шуннан соң бетерелергә тиеш.

1.12. Конкурста катнашу (конкурс үткәрү урынына бару һәм кире кайту, торак урынны наемга алу, яшәү, элемтә чаралары хезмәтеннән файдалану һ.б.) белән бәйле чыгымнар кандидатлар тарафыннан үз акчалары исәбеннән түләнә.

## II. Конкурс комиссиясен төзү һәм эш тәртибе

2.1. Министрлыкта конкурслар уздыру өчен министр боерыгы нигезендә даими нигездә эшләүче конкурс комиссиясе төзелә. Конкурс комиссиясе эшенең объективлылык һәм бәйсезлек дәрәҗәсен арттыру һәм төрле категорияләрдәге гражданнар хезмәте вазыйфаларының төркемнәре өчен конкурсларны нәтиҗәле оештыру максатында, министр карары буенча аның составы үзгәртелә. Комиссия составы министр боерыгы белән раслана.

2.2. Конкурс комиссиясе рәисе, рәис урынбасары, секретарь һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

2.3. Комиссия рәисе конкурс комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмый торганда, аның хокукларын һәм вазыйфаларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Конкурс комиссиясе секретаре комиссия эшен (гаризалар кабул итү, эшләр формалаштыру, конкурс комиссиясе карарларын рәсмиләштерү һ.б.) тәэмин итә.

2.4. Конкурс комиссиясе составына министр һәм (яки) ул вәкаләт биргән граждан хезмәткәрләре (шул исәптән вакантлы граждан хезмәте вазыйфасын биләүгә конкурс уздырыла торган кадрлар бүлегеннән дә (кадрлар резервына кертү өчен конкурс уздырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеме буенча һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсе гамәлгә ашырыла торган бүлекчәдән)), Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук законнарда билгеләнгән тәртиптә министрның рәсми мөрәҗәгате буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан чакыртыла торган, кадр технологияләре һәм граждан хезмәте мәсьәләләре буенча бәйсез экспертлар – тиешле өлкәләрдә һәм граждан хезмәтенең һөнәри хезмәт эшчәнлеге төрләрендә белгечләр булып торган фәнни, мәгариф һәм башка оешмаларның вәкилләре керә. Бәйсез экспертның конкурс комиссиясендә булу вакыты өч елдан артмаска тиеш.

Министрлык каршынлагы Иҗтимагый совет әгъзаларының һәм бәйсез экспертларның гомуми исәбендә конкурс комиссиясендәге барлык әгъзаларының исәбе кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итә.

2.5. Алар буенча вазыйфаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил иткән белешмәләрдән файдалануга бәйле булган граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздырылганда конкурс комиссиясе составы Россия Федерациясенең дәүләт сере турында законнары нигезләмәләрен исәпкә алып төзелә.

2.6. Конкурс комиссиясе составы, конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгать каршылыклары барлыкка килү ихтималы булмаслык итеп төзелә.

2.7. Конкурс комиссиясе утырышы граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервына кертү өчен) кимендә ике кандидат булганда үткәрелә һәм, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала. Конкурс комиссиясе утырышын бары тик граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче әгъзалар катнашында гына уздыру рөхсәт ителми.

2.8. Кандидат белән турыдан-туры шәхси әңгәмә үткәрмичә генә конкурс комиссиясе тарафыннан конкурста җиңүчене билгеләү турында карар кабул итү рөхсәт ителми.

Конкурс комиссиясе тарафыннан утырышны аның әгъзасы яки кандидаты тәкъдиме белән, мондый карар сәбәбен (нигезен) күрсәтеп, видеоконференция форматында (техник мөмкинлек булган очракта) уздыру турында конкурс комиссиясе карары кабул ителергә мөмкин.

2.9. Конкурс комиссиясе карары кандидат юклыгында кабул ителә.

2.10. Конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучы әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.

2.11. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү буенча конкурс йомгаклары буенча комиссиянең тавыш бирү нәтиҗәләре әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасына туры китерелгән формада конкурс комиссиясе карары белән рәсмиләштерелә. Кадрлар резервына керү буенча конкурс йомгаклары буенча комиссиянең тавыш бирү нәтиҗәләре әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасына туры китерелгән формада конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

Әлеге карар һәм беркетмәдә конкурс комиссиясе тарафыннан бәяләү нәтиҗәләре буенча тупланган балларын һәм алар биләгән урыннарны күрсәткән рейтинг була.

2.12. Конкурс комиссиясе эшен оештыруны һәм тәэмин итүне Министрлыкның кадрлар бүлеге гамәлгә ашыра.

## III. Конкурста катнашучылар

3.1. Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) буенча кандидатларга карата таләпләргә җавап бирә торган һәм шушы Нигезләмәнең 3.7 пункты белән күздә тотылган чорда әлеге Нигезләмәнең 3.4 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырган гражданнар конкурста катнашуга кертелә.

3.2. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасына) карата квалификация таләпләренә җавап бирмәве, шулай ук Федераль законда билгеләнгән чикләүләренә бәйле рәвештә гражданин (граждан хезмәткәре) конкурста катнашуга кертелми.

3.3. Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен кандидатларга карата таләпләр дәүләт граждан хезмәте турындагы Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән.

3.4. Россия Федерациясенең конкурста катнашырга теләк белдергән гражданины Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасына туры китерелгән формада шәхси гариза;

Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган форма буенча тутырылган һәм имзаланган анкета, фотография белән;

паспорт яки аны алмаштыра торган документ (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә) күчермәсе;

кирәкле һөнәри белем, квалификацияне һәм эш стажын раслаучы документлар:

хезмәт (эш) урыны буенча нотариаль яки кадрлар хезмәте тарафыннан расланган хезмәт кенәгәсе күчермәсе һәм (яисә) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар һәм (яисә) гражданинның хезмәт (эш) эшчәнлеген раслаучы башка документлар (хезмәт (эш) эшчәнлеге беренче тапкыр башкарыла торган очраклардан тыш);

белеме турында һәм квалификациясе турында документларның күчермәләре, шулай ук, ихтыяры буенча, өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча квалификациясен күтәрүне яки бирелүне раслый торган документларның, фәнни дәрәҗә, фәнни исем бирелү турында документларның нотариаль яктан яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәсе;

гражданинда граждан хезмәтенә керүгә яки аны үтүгә комачаулый торган чирләрнең булмавы турында документ (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәткәрләре һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан диспансеризация узу тәртибен, Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенә һәм муниципаль хезмәткә керү һәм аны узу өчен каршылык тудыра торган авырулар исемлеген, шулай ук медицина оешмасы бәяләмәсе формасын раслау турында» 2009 елның 14 декабрендәге 984н номерлы боерыгы белән расланган 001-ГС/у исәпкә алу формасы);

Федераль законда, башка федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган бүтән документлар.

3.5. Министрлыкта граждан хезмәте вазыйфасын биләп торучы һәм конкурста катнашырга теләк белдергән граждан хезмәткәре бары тик министр исеменә гариза тапшыра.

Башка дәүләт органында вазыйфа биләүче, конкурста катнашу теләген белдергән граждан хезмәткәре Министрлыкка министр исеменә шәхси гариза һәм үзе тутырган, имзалаган һәм үзе граждан хезмәтен били торган дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган, Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган формадагы анкетаны фотосын теркәп тапшыра.

3.6. Гражданинның (граждан хезмәткәренең) ризалыгы белән аңа дәүләт серен яки закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга рөхсәт бирү процедурасы рәсмиләштерелә, әгәр дә гражданин (граждан хезмәткәре) тарафыннан биләү өчен дәгъва белдерелгән граждан хезмәте вазыйфасы

буенча вазыйфаи бурычларны үтәү мондый белешмәләрдән файдалануга бәйле булса.

Гражданинның министр исеменә тапшырылган белешмәләренең дөрес булу-булмавы тикшерелергә тиеш. Электрон рәвештә тапшырылган белешмәләр Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә автоматлаштырылган рәвештә тикшерелә.

3.7. Әлеге Нигезләмәнең 3.4 һәм 3.5 пунктларында күрсәтелгән документлар аларны кабул итү турында «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмат системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында (алга таба – Федераль мәгълүмат системасы) игълан урнаштырылган көннән башлап 21 календарь көне эчендә Министрлыкка гражданин (граждан хезмәткәре) тарафыннан шәхсән, почта аша җибәреп яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә Федераль мәгълүмат системасыннан файдаланып, электрон рәвештә җибәрелә.

Документларны игътибарга лаек сәбәпсез вакытында тапшырмау, аларны тулы булмаган күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданиннан (граждан хезмәткәреннән) аларны кабул итеп алудан баш тарту өчен нигез булып тора.

Хөрмәткә лаек сәбәп аркасында документларны үз вакытында тапшырмаганда, аларны тулы булмаган күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшырганда министр аларны кабул итү вакытын күчерергә хокуклы.

## IV. Конкурсны уздыру методикасы

4.1. Конкурсларны уздыруга әзерлек кандидатларның профессиональ һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларын (алга таба – бәяләү методлары) сайлауны һәм аларга туры килә торган конкурс биремнәрен формалаштыруны, зарурлык булганда граждан хезмәтенең аларны биләү буенча конкурс игълан итү планлаштырыла торган вакантлы вазыйфаларына карата граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи регламентлары нигезләмәләрен актуальләштерүне күздә тота.

4.2. Граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи регламентларының нигезләмәләрен актуальләштерү, бәяләү методларын сайлау һәм аларга туры килә торган конкурс биремнәрен формалаштыру Министрлыкның мәнфәгатьле бүлекчәсе тарафыннан кадрлар бүлеге белән килештереп гамәлгә ашырыла. Конкурс комиссиясе әгъзалары бәяләү методларын куллану һәм конкурс биремнәрен формалаштыру турында тәкъдимнәр кертергә хокуклы.

Министр карары нигезендә граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи регламентларында граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларына карата конкрет белгечлеккә (әзерлек юнәлешенә) карата квалификация таләпләре куелырга мөмкин.

4.3. Кандидатларның профессиональ дәрәҗәсен, аларның квалификация таләпләренә туры килүен бәяләү өчен конкурс процедуралары барышында, әңгәмә, анкета,

төркемле дискуссияләр уздыруны, документ проектын әзерләүне, реферат һәм язмача башка эшләр язуны, гамәли мәсьәләләр чишүне яки вакантлы граждан хезмәте вазыйфасы (граждан хезмәтенең кадрлар резервы формалаштырыла торган вазыйфалар төркеме) буенча вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча тест уздыруны да кертеп, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына каршы килми торган бәяләү методлары кулланылырга мөмкин.

4.4. Конкурс ике этапта үткәрелә.

4.5. Беренче этапта Министрлыкның кадрлар бүлеге түбәндәгеләрне оештыра:

конкурс уздырылуы турында мәгълүмат әзерли һәм Министрлыкның һәм Федераль мәгълүмат системасының рәсми сайтларында урнаштыра, анда түбәндәгеләр күрсәтелә: граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасының (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасының) аталышы, әлеге вазыйфаны биләү өчен квалификация таләпләре, дәүләт граждан хезмәтен узу шартлары, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен кандидатлар тарафыннан тапшырыла торган документлар һәм материаллар исемлеге нигезендә тапшырылырга тиешле документларны Министрлыкта кабул итү урыны һәм вакыты, әлеге документларны кабул итү срогы, конкурс уздыруның күздә тотылган датасы, аны уздыру урыны һәм тәртибе, бәяләү методлары турында белешмәләр, граждан хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын, хокукларын һәм вазыйфаи бурычларны үтәмәгән (тиешенчә үтәмәгән) өчен җаваплылыкны үз эченә алган вазыйфаи регламент нигезләмәләре, граждан хезмәткәренең профессиональ хезмәт эшчәнлегенең файдалылык һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре, Федераль мәгълүмат системасында урнаштырылган беренчел квалификация тестына сылтама, башка мәгълүмат материаллары;

кандидатлар тарафыннан тапшырылган документларны тикшерү;

гражданинның (граждан хезмәткәренең) квалификация таләпләренә туры килүен тикшерә (һөнәри белем дәрәҗәсе, граждан хезмәте (башка граждан хезмәтенең) стажы яки белгечлеге буенча эшләү стажы (тәҗрибәсе), әзерлек юнәлеше, вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле булган һөнәри белемнәре һәм күнекмәләре).

4.6. Дәгъва белдерүче конкурстан тыш үзенең профессиональ дәрәҗәсен мөстәкыйль бәяләү өчен беренчел квалификация тестын узарга мөмкин, бу хакта конкурс игъланында күрсәтелә.

Беренчел тестта дәгъва белдерүчеләрнең Россия Федерациясе дәүләт телен (рус телен) белү дәрәҗәсен, Россия Федерациясе Конституциясе нигезләре, дәүләт хезмәте турында һәм коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнары турындагы белемнәрен, мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендәге белемнәрен һәм күнекмәләрен бәяләү өчен биремнәр була.

Беренчел тест Федераль мәгълүмат системасы рәсми сайтында урнаштырыла,

аны узу мөмкинлеге дәгъва белдерүчеләр өчен түләүсез нигездә бирелә.

Дәгъва белдерүче тарафыннан беренчел тест үтү нәтиҗәләре конкурс комиссиясе тарафыннан игътибарга алына алмый һәм конкурста катнашу өчен документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

4.7. Тикшерү барышында гражданинның Федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә граждан хезмәтенә керүенә комачау итүче шартлар ачыкланган очракта, аңа конкурста катнаштырудан кире кагуның сәбәпләре турында министр тарафыннан язмача рәвештә хәбәр ителә. Әгәр гражданин конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган булса, конкурста катнаштырудан баш тарту сәбәпләре хакында хәбәр аңа, Федераль мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә.

4.8. Конкурста катнашуга кертелмәгән, вакантлы вазыйфаны биләп торуга дәгъва белдерүче зат әлеге карарга Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять бирергә хокуклы.

4.9. Министрлыкта граждан хезмәтенең бер вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасына) карата куелган квалификация таләпләренә җавап бирә торган кимендә ике кандидатның булуы конкурсның беренче этабын төгәлләү шарты булып тора, бу хәл кандидатларны алга таба сайлау мөмкинлеген тәэмин итә.

Кандидатлар булмаса яки вазыйфага квалификация таләпләренә туры килә торган бер генә кандидат булса, конкурс узмаган дип танылა. Бу очракта бердәнбер кандидатка, кандидатларның таләп ителә торган саны булмау сәбәпле, конкурс үткәрелмәгән дип хәбәр ителә.

4.10. Конкурсның беренче этабы тәмамлангач министр конкурсның икенче этабын уздыру датасы (катнашу өчен документлар кабул итү тәмамланганнан соң 30 календарь көне узганчы), вакыты һәм урыны турында карар кабул итә. Дәүләт серен һәм закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга рөхсәт рәсмиләштерелгән очракта, конкурсның икенче этабын уздыру чорын министр билгели.

Кадрлар бүлеге, конкурсның икенче этабы башланырга 15 календарь көне узганчы, Министрлыкның һәм Федераль мәгълүмат системасы рәсми сайтларында аны уздыруның датасы, урыны һәм вакыты турында мәгълүмат, конкурста катнашуга кертелгән кандидатларның исемлеген урнаштыра һәм кандидатларга язмача рәвештә тиешле хәбәрләмәләрне җибәрә, бу вакытта конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган кандидатларга, – Федераль мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында.

4.11. Конкурсның икенче этабында түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

«Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – Кадрларның бердәм мәгълүмат системасы) кандидатлар турында мәгълүмат кертелә;

кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын конкурс комиссиясе тарафыннан бәяләү;

Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурста җиңүчене билгеләү турында конкурс комиссиясе карары кабул ителә;

Кадрларның бердәм мәгълүмат системасында конкурс нәтиҗәләрен рәсмиләштерү;

Министрлыкның һәм Федераль мәгълүмат системасы сайтларында конкурс нәтиҗәләре бастырып чыгарыла.

4.12. Конкурс уздырганда конкурс комиссиясе кандидатларны алар тарафыннан тапшырылган белеме, граждан яисә башка төрле дәүләт хезмәтен узуы, башка төрле хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыруы турындагы документлар нигезендә, шулай ук тест, анкета уздыруны, шәхси әңгәмә уздыруны, реферат яки башка төрле язмача эшләр язуны, документ проектын әзерләүне үз эченә алырга мөмкин булган бәяләү методларын кулланып, конкурс процедуралары нәтиҗәләре нигезендә бәяли. Конкурс үткәрелә торган төркем һәм вазыйфалар категориясенә карап, төрле ысуллар кулланыла ала. Бу вакытта кандидат белән тест һәм индивидуаль әңгәмә уздыру барлык кандидатлар өчен дә мәҗбүри методлар булып тора.

Министрлык тарафыннан конкурс комиссиясе эшчәнлеге, шулай ук кандидатлар тарафыннан конкурс процедураларын узу өчен тиешле оештыру һәм матди-техник шартлар тудырыла.

4.12.1. Анкеталау структур бүлекчә җитәкчесе тарафыннан конкурс үткәрелә торган мәсьәләләр буенча яисә граждан хезмәте вазыйфалары төркеме буенча кадрлар резервына кертүгә конкурс үткәрелә торган, һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсе гамәлгә ашырыла торган структур бүлекчәләр җитәкчеләре тарафыннан үткәрелә.

Анкетага элегрәк гамәлгә ашырылган профессиональ эшчәнлек буенча үтәлә торган вазыйфаи бурычлар, профессиональ казанышлар, кандидат катнашкан чаралар (проектлар, форумнар, семинарлар һ.б.), басма матбугатларда аның мәкаләләре, мавыгулары турында, шулай ук аның тарафыннан тапшырылырга мөмкин булган тәкъдимнәр һәм (яки) турында тәкъдим хатлары турында сораулар кертелә.

Анкетага шулай ук кандидатның мотивациясен бәяләүгә юнәлдерелгән өстәмә сораулар да кертелергә мөмкин.

Конкурс комиссиясе утырышына кадәр 10 календарь көне кала кандидатларга

анкета формасы җибәрелә. Тутырылган анкета конкурс комиссиясе утырышына кимендә биш календарь көненнән соңга калмыйча кандидатлар тарафыннан конкурс комиссиясе секретаренә тапшырыла.

Анкета сорауларына җаваплар өчен бәяләр куелмый.

Кандидатларның анкеталары шәхси әңгәмә вакытында тыңлана.

